**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**С О В Е Т**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 81** **2018 елның 19 декабре**

**Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милегенә ия булу, файдалану һәм аның белән идарә итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 22 декабрендәге 40 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 30 маддәсе нигезендә, муниципаль милектән нәтиҗәле файдалану һәм идарә итү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милегенә ия булу, файдалану һәм аның белән идарә итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 22 декабрендәге 40 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Нигезләмәнең 12 бүлегенең 12.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.3. Бушлай файдалану шартнамәсе аны гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә яңа срокка төзү мөмкинлеге белән ун елдан артык булмаган вакытка төзелә».

- Нигезләмәнең 12 бүлеген 12.17 пункты белән түбәндәге редакциядә тулыландырырга:

«12.17. Муниципаль мөлкәтне җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырганда, алар тарафыннан күрсәтелгән мөлкәтне функцияләр (вәкаләтләр), шул исәптән тапшырылган, башкару кысаларында файдалану максатларында, әлеге мөлкәтне карап тоту бурычы Ссуда бирүчегә йөкләнә».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы А.Р. Метшин